ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КАЛМИЯ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

**КАРАР**

«03» апрель 2024 ел Калмия авылы №9

**«Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Калмия авыл җирлеге составына керүче Малтабар авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 17 октябрендәге 1 номерлы гражданнар җыены карарына һәм 2023 елның 17 октябрендәге 2 номерлы Тукай муниципаль районы Калмия авыл җирлеге Малтабар авылында гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Калмия авыл җирлеге Малтабар авылында гражданнар җыенын билгеләү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Тукай муниципаль районы «Калмия авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы, «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының Калмия авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында» нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Калмия авыл җирлеге Советының 2019 елның 30 октябрендәге 9/2 номерлы карары нигезендә

**КАРАР БИРӘМ:**

1. «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Калмия авыл җирлеге составына керүче Малтабар авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 17 октябрендәге 1 номерлы гражданнар җыены карарына һәм 2023 елның 17 октябрендәге 2 номерлы Тукай муниципаль районы Калмия авыл җирлеге Малтабар авылында гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча 2024 елның 14 апреленә 16.00 сәгатькә гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез үзгәрешләр кертергә ризамы:

1) түбәндәге редакциядә бәян итеп, гражданнар җыенына чыгарылган һәм кабул ителгән «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Калмия авыл җирлеге составына керүче Малтабар авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 17 октябрендәге 1 номерлы гражданнар җыены карарына:

«- традицион җирләү урыннарын ремонтлау, коймалар урнаштыру, төзекләндерү (Малтабар авылының зиратын төзекләндерү, зиратка койма сатып алу һәм урнаштыру)»;

2) түбәндәге редакциядә бәян итеп, 2023 елның 17 октябрендәге 2 номерлы Тукай муниципаль районы Калмия авыл җирлеге Малтабар авылында гражданнар җыены карарына:

«- традицион җирләү урыннарын ремонтлау, коймалар урнаштыру, төзекләндерү (Малтабар авылының зиратын төзекләндерү, зиратка койма сатып алу һәм урнаштыру)».

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Гражданнар җыенын түбәндәге адрес буенча үткәрергә: Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы, Калмия авыл җирлеге, Малтабар авылы, Октябрьская , 12Б йорты (башлангыч мәктәп бинасы).

4. Халык җыенын оештыручы итеп Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы Калмия авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Калмия авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә махсус мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (tukay.tatarsatan.ru) урнаштырырга.

6. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Тукай муниципаль районы
Калмия авыл җирлеге Башлыгы
вазыйфаларын башкаручы Р.М.Харрасова